СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

4 октябрь, 1997ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.

№ 112 (8124)

Бәясе билгеләнгәнчә

# Егетлекне сынап басуда

Әле кайчан гына диңгездәй җәйрәп яткан шикәр чөгендере басуы күз алдында кимеде.Бер-бер артлы тезелеп киткән агрегатлар кырның яшел өлешен «кимерепме кимерәләр».

-Техника гына түзсен, үзебез сынатмабыз,-диде безгә звено җитәкчеләренең берсе-район күләмендә танылган Әсхәт Тәмаев.Анысы,сынатмаслыклары расланган инде.Әнә, Әсхәтнең «ДОН-1500» белән 15 мең центнерлап ашлык суктырып,комбайнын мастерскойга куйганына да санаулы көннәр генә узды әле. Инде монда үз биләмәсендәге 90 гектарлы кырда чөгендерне казытып бетереп бара.Бик газиз,бик кадерле шул бу җир аның өчен.Т-70 тракторы белән язын биредә орлык күмдергән иде,җәй буе үсемлекләрне карап, эшкәртеп торды.Моның җимешләре дә мул булды:чөгендернең берсе-берсе дә 500 грамм тартыр,билләхи! Шатланып,сөенеп эшли шуңа.

Дөрес,техникалары сынаткалый. Әмма чөгендер казыту агрегатлары хуҗалыкка кайткан көннән шуңа утырып эшләүче механизаторлар аларның бөтен «серләрен» беләләр:ватылган-ниткән очракта яннан ярдәм көтмичә үзләре үк төзәтеп тә куялар.БМ-6 комбайнчысы Вазыйх Ибәтуллин,чистарткыч агрегат йөртүче Салих Гомәров, кем әйтмешли, кендекләре белән җиргә береккән кешеләр бит. Комбайннан чөгендерне кагатларга ташучы «КамАЗ»чы Равил Әбделмәнов,МТЗ-80 тракторчысы Рәшит Абдуллин да тырышлар. Соңгысы мәктәпне быел гына тәмамлаган егет. «Беларус»е руле артыннан башы бик аз гына күренсә дә, өлкәннәрнең күзләренә генә карап торып,кул ишарәләреннән үк барысын да аңлап эшли.

-Бер дигән механизатор чыга Рәшиттән.Үзебезнең звенога даими эшкә алабыз үзен,-диләр чөгендерчеләр.

Димәк,хуҗалыкның тагын бер ышанычлы механизаторы арта. Югары Норлатның танылган чөгендер игү осталары Шамил ага Яруллин һәм Зәйдулла ага Мөхәммәтов та шулай,яшьли, буразна арасыннан башлап, оста булып киткәннәр бит.Һичкайчан сынатмаулары да шуннан килә.Әнә,быел,190 гектарлы мәйдандагы чөгендерне 10 көн эчендә казыдылар да чыктылар бит!

Түбән Норлаттагы тагын бер звено- Әнвәр Вәлиев җитәкчелегендәгесе турында әйтми калу мөмкин түгел.Коллектив башлыгы-уңган, булган,шушы җирдә эшләп,кем әйтмешли азау теше чыккан кеше.Шушы мәйданга чөгендерне үзе чәчкән, үсентеләрне үзе үк карап та үстергән. Бүген КС-6 комбайны белән чөгендер казыта.Фәрит Абдуллин,Фәнил Сафин яфрак урдыру,чистарту белән мәшгульләр. Тракторчылар Хафиз Халитов һәм Фәрхәть Газизов исә чөгендерне кагатларга ташыйлар. Барысы да бер йодрыкка тупланып,бер максат-плантацияләр уңышын тиз арада җыеп алып, хәзерләүләр пунктына озату өчен тырышалар.

...Авылда урак өсте дәрте сүрелмәгән, укучылар, мәктәп, балалар бакчасы, хуҗалыкның бухгалтерия, ашханә хезмәткәрләре,чөгендерче хатын-кызлар гомумән,авылда яшәүче һәм булышырлык рәте булган һәркемнең бүген чөгендер басуында булуы да шул хакта сөйли.

-Һәр гектардан 300 центнер уңыш җыеп алып, шикәр заводына 7200 тонна чимал тапшыру-безнең өчен реаль бурыч,-ди ассоциация рәисе Й.Г.Әхмәтсафин.

-Буш сүзләр түгел болар,- дип өстәде район авыл хуҗалыгы идарәсенең үсемлекчелек бүлеге начальнигы Н.М.Мусин.-Әлеге хуҗалыкның шикәр чөгендере игүдә үзенә генә хас,үзенә генә мәгълүм тәҗрибәсе бар.Нургали Мингалиевичның кондырчалыларның җиргә мөнәсәбәте,кайгыртучан карашы турында әйтүе иде: көздән үк чөгендер кыры яхшы итеп сөрелеп,эшкәртелеп,ашланып калдырыла. Көзге культивация, сөрү катламын тирәнәйтү, тигезләү һәм боларның барысы нәтиҗәсе буларак иртә яздан орлык күмдерү.Әҗир кайгыртуга һәрчак юмарт.

Р.ГИНЯЕВА.

**Фоторепортаж**





Рәсемнәрдә: Ә.Вәлиев звеносы эштә; менә ул киләчәк игенчесе - Р.Абдуллин.

## «Уңыш - 97» матбугат үзәге хәбәр итә

**Шикәр чөгендере кичәге көнгә барлык мәйданның 44 процентыннан казып алынды. Алдан аяк киенгән хуҗалыкларда андый мәйданнар шактый үк ишле инде. «Дуслык»та аны тулысынча чыгарып бетерделәр, «Кондырча»да чөгендерне казу планы 83,«Төрнәс»тә 76, «Якты Күл»дә 65 процентка үтәлде.**

**Чөгендерне барлык мәйданның яртысыннан казып алган шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгы аны дәүләткә сату планын 62 процентка үтәде инде. 2 октябрьгә булган мәгълүматлар буенча «Кондырча»да бу төр план 40, Кузнецов исемендәге хуҗалыкта 35 процентка башкарылды.**

**Кукурузны орлык өчен алуга Хафизов исемендәге, «Родина», «Таң» хуҗалыкларында да керештеләр, ә «Кондырча»да бу эш санаулы гектарларда гына калды инде. Әмма күп хуҗалыклар һаман да нәрсәдер көтәләр әле.**

**Туңга сөрү планы 75 процентка үтәлде. Ул эшне нигездә тәмамлаган хуҗалыклардагы техниканы туңга сөрү бик авырлык белән барган хуҗалыкларга ярдәмгә җибәрми булмастыр.**

# 5 ОКТЯБРЬ - УКЫТУЧЫЛАР КӨНЕ

## *Бәйрәм белән, хөрмәтле педагоглар!*

***Укытучы. Шушы исемне әйтүгә күз алдыбызга сабыр,киң күңелле,шул ук вакытта үз-үзенә һәм башкаларга таләпчән,кешеләрне тыңлый,бала күңелен аңлый белә торган,көчле рухлы,үз фикерен ачык итеп дәлилли алучы,дөрес һәм матур сөйли белүче кеше килеп баса.Шуңа да безнең һәркайсыбыз үзенең аякка басуы белән иң әүвәл укытучыларына рәхмәтле.Укытучыларга гомер буе ихтирам хисе саклау да шуңардан килә.***

***Шунысы куанычлы,районыбызда иҗади эшләүче педагогик коллективлар байтак.Бүген идеологик юнәлешләр чуалган чакта да алар үзләренең төп һәм гадел принциплары - балаларга белем һәм тәрбия бирү эшенә,аларга карата мәхәббәт һәм ихтирам хисенә турылыклы калалар.***

***Укытучылар,тәрбиячеләр алдына куелган бурычлар киң һәм катлаулы.Шуларның иң мөһиме-балаларны ныклы белем белән коралландыру,аларны тормышка хәзерләү.Әйтергә кирәк,район педагоглары бу бурычларны уңышлы тормышка ашыру өчен сәләт-көчләрен кызганмыйлар.***

***Хөрмәтле укытучылар! Район хакимияте, халык депутатларының район Советы президиумы сезне һөнәри бәйрәмегез белән чын күңелдән котлап,сез,җаваплы һөнәр ияләренә тирән ихтирам белдереп, сәламәтлек,бәхет,иҗади хезмәтегездә уңышлар тели.***

***Ф.СИБАГАТУЛЛИН,***
***халык депутатларының район Советы рәисе,район хакимияте башлыгы.***

## Вице - премьер ветераннар белән очрашты

1 октябрьдә, чәршәмбе көнне районда өлкәннәр ункөнлеге кысаларында Республика вице - премьеры И.К.Хәйруллин булды. Аның визитының максаты районда бу катлау кешеләрнең мәнфәгатьләрен социаль яклау эше практикасын өйрәнү иде. Бу көнне ул Халыкара өлкәннәр көне уңаеннан район мәдәният йортында үткәрелгән бәйрәм тантанасында катнашып чыгыш ясады, күпсанлы очрашуларда сугыш һәм хезмәт ветераннарының тормышы һәм яшәү - көнкүреш шартлары, Норлатта бала тудыру йорты төзелешенең барышы белән кызыксынды. Вице - премьер шулай ук «Норлат - Октябрь элеваторы» АҖндә булды. Бу көннәрдә районда Республиканың Социаль тәэминат, Элемтә, Торак - комммуналь хуҗалыгы министрлыклары, Татпотребсоюз, «Татавтотранс» һәм Республика ВТЭК вәкилләре составында аналитик - мәгълүмат төркеме дә эшләде. Районда өлкәннәр көнен оештыру турындагы тәфсиллерәк язманы газетабызның чираттагы санынннан укырсыз.

## Хезмәтен хөрмәтләп

Татарстан Республикасы Президенты Указы белән район хакимиятенең мәгариф бүлеге район методик кабинеты мөдире **Венера Мөхәммәдиевна Камаловага** «Татарстан Республикасы мәктәпләренең атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирелде.

## *Хакимият башлыгы котлый*

**Районда урак тәмамланса да, кырларда авыл хуҗалыгы эшләре дәвам итә әле һәм авыл эшчәннәре намуслы һәм фидакарь хезмәт үрнәкләре күрсәтәләр.**

**Бу көннәрдә туңга сөрүдә алдынгы булган механизаторлар Наил Гыйбадулла улы Кадыйров («Якты Күл»), Илһам Илдус улы Сәлимгәрәев («Алга») һәм Дамир Салих улы Латыйпов (М.Җәлил исем.),чөгендер казуда заданиене арттырып үтәүчеләр Зәйдулла Зәйнетдин улы Мөхәммәтов һәм Шәмил Әхмәдулла улы Яруллин («Кондырча»), Рәдиф Хәниф улы Кәримов («Киекле») һәм Касыйм Миннеәхмәт улы Саттаров («Рассвет») район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин исеменнән котлау һәм иң изге теләкләр белән рәхмәт хатлары алдылар.**

## *Хөрмәтле дуслар!*

**1998 елның беренче яртыеллыгына газетага язылу бара. Язылу бәясе ярты елга 26.400, өч айга - 13.200, бер айга - 4.400 сум.**

**Район газетасына язылырга ашыгыгыз! Ул һәрвакыттагыча сезгә яңалыклар, хәбәрләр, кызыклы киңәшләр белән бергә атналык телетапшырулар программасын да даими биреп барачак.**

# TV

**ПОНЕДЕЛЬНИК,
6 октября
«ТАТАРСТАН»**

7.00 - 8.00 "Чулпан"
17.30 Мультфильм
17.55 Балалар өчен "Тамчы"
18.10 "Бизнес TV"
18.45, 20.45 "Җиһан" хәбәрләр 19.00 "Замандаш" цикльннан 19.30 "Загадки страны золотого цвета"
19.45, 21.45 Новости
20.00 "Баскетбол, мы тебя любим!"
20.30 "Әлли - бәлли - бәү"
21.00 "Через тернии - к звездам".
22.25 "Карт - бланш". Анатолий Торкунов.
22.55 Программа передач

**ОРТ**

6.00 Телеканал "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба". Сериал.
10.00 Поле чудес.
11.00 Здоровье.
11.30 "Угадай мелодию".
15.20 "Драконы подземелий".
15.45 Марафон-15.
16.05 Звездный час.
16.40 "Космическая полиция".
17.05 ...До шестнадцати и старше.
17.30 Премьера сериала "100 лет приключений".
18.00 Новости.
19.00 Погода.
19.10 Час пик.
19.35 "Угадай мелодию".
20.05 Программа "Мы".
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.40 Программа передач.
21.45 "Дрожь Земли".
23.30 "Серебряный шар". Одри Хепберн.
0.15 "Женская роль".
1.15 Новости.

**"РОССИЯ"**

7.10 "Дон Кихот Ламанчский".
7.35 Справочная "Медицина для вас".
7.40 Вовремя.
7.45 Монетный двор.
8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
8.20 "Дежурная часть".
8.35 "Жизнь Дэвида Копперфилда, рассказанная им самим". 1-я серия.
9.35 Документальный экран. "История одного события".
9.50 10.50 "Товары - почтой".
10.00 "Санта-Барбара".
11.20 L-клуб.
11.50 Совершенно секретно.
12.45 "Музыкальный экспромт".
13.00 Сам себе режиссер.
13.30 Парламентский вестник.
13.55 "Магазин недвижимости".
14.20 "Деловой автограф".
14.25 "ТИ-Маркет".
14.30 "Путь домой". Х/ф.
15.55 Музыка на десерт.
16.10 Графоман.
16.20 "Лучше не бывает".
16.25 "Эксповестник".
16.30 На пороге века.
16.55 Прогноз погоды.
17.20 "Православный календарь".
20.35 Национальный интерес.
21.10 Творческий вечер А.Розенбаума.
23.20 Вовремя.
23.25 Добрый вечер.
0.10 "Дежурная часть".
0.25 Лестница в небо.
0.55 Прогноз погоды.
1.00 "Товары - почтой".

**ВТОРНИК,
7 ОКТЯБРЯ
«ТАТАРСТАН»**

7.00 - 8.00 "Чулпан".
17.30 Мультфильм
18.00 "Сельские будни"
18.30 Хоккей. Чемпионат РХЛ
20.35 Әлли - бәлли -бәү
20.45 "Җиһан" хәбәрләр
21.00 "Через тернии - к звездам"
21.45 Новости
22.25 "Карт - бланш"

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.55 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба".
10.00 Программа В.Познера "Мы".
10.40 Смехопанорама.
11.20 Домашняя библиотека.
11.30 19.35 "Угадай мелодию"
15.20 "Драконы подземелий".
15.45 Кварьете "Веселая квампания".
15.55 Счастливый случай.
16.40 "Космическая полиция".
17.05 ...До шестнадцати и старше.
17.30 "100 лет приключений"
19.00 Погода.
19.10 Час пик.
20.00 Тема.
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.40 Программа передач.
21.45 "Летние люди". Х/ф.
23.30 Хоккей. Евролига. "Торпедо" (Ярославль) - "Слован" (Братислава).

**"РОССИЯ"**

7.10 "Дон Кихот Ламанчский".
7.35 "Стронг" представляет.
7.40 23.20 Вовремя.
7.45 Монетный двор.
8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
8.20 "Дежурная часть".
8.35 18.55 "Жизнь Дэвида Копперфилда, рассказанная им самим". 2-я серия.
9.35 18.40 "История одного события".
10.00 17.25 "Санта-Барбара"
11.20 11.48 20.35 Национальный интерес.
13.25 Пульс.
13.55 "Магазин недвижимости".
14.20 "Деловой автограф".
14.25 "Регион Кузбасс".
14.30 "Рогоносец". Х. ф.
16.10 Графоман.
16.20 "Лучше не бывает".
16.25 "Эксповестник".
16.30 Новое пятое колесо.
16.55 Прогноз погоды.
17.20 "Православный календарь".
18.20 Лукоморье
21.10 "Сиси и поцелуй императора".
22.50 "Мой Пушкин".
23.00 Вести.
23.25 Добрый вечер.
0.10 "Дежурная часть".
0.25 Горячая десятка.
1.20 Прогноз погоды.
1.24 "Товары - почтой".

**СРЕДА,
8 ОКТЯБРЯ
«ТАТАРСТАН»**

7.00-8.00 "Чулпан"
17.30 Мультфильм
18.00 Баскетбол. Кубок Корача.
19.45,21.45 Новости
20.00 "Точка опоры"
20.20 "Пульс"
20.35 "Әлли - бәлли - бәү"
20.45 "Җиһан" хәбәрләр
21.00 "Возвращенте Святого Луки".
22.25 Программа передач

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.25 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба".
10.00 Тема.
10.40 В мире животных
11.15 Домашняя библиотека.
11.25 "Джентльмен-шоу".
15.20 "Драконы подземелий". Мультсериал.
15.45 Кактус и К.
15.55 До-ми-соль.
16.15 Зов джунглей.
16.40 "Космическая полиция".
17.05 ...До шестнадцати и старше.
17.30 "100 лет приключений"
19.00 Погода.
19.10 Час пик.
19.35 "Золотая лихорадка". Х/ф.
20.10 Человек и закон.
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.40 Программа передач.
21.45 "Трое мужчин и младенец в люльке". Х/ф.
23.40 "Западня для "Шейха".

**"РОССИЯ"**

7.10 "Дон Кихот Ламанчский".
7.35 "Стронг" представляет.
7.40 23.20 Вовремя.
7.45 Монетный двор.
8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
8.20 "Дежурная часть".
8.35 18.50 "Жизнь Дэвида Копперфилда, рассказанная им самим".
9.40 18.35 "История одного события".
10.00 17.25 "Санта-Барбара".
11.20 Национальный интерес.
11.50 "Перпендикулярное кино".
12.45 Слабо?
13.15 Федерация.
13.40 Графоман.
13.55 "Магазин недвижимости".
14.20 "Деловой автограф".
14.25 "ТИ-Маркет".
14.30 "Коппелия". Художественный фильм.
16.20 "Лучше не бывает".
16.25 "Эксповестник".
16.30 Золотая карта России.
17.20 "Православный календарь".
18.15 Лукоморье
20.35 Национальный интерес.
21.05 "Пурпурная роза Каира".
22.35 23.25 Добрый вечер.
0.10 "Дежурная часть".
0.25 Лестница в небо.

**ЧЕТВЕРГ,
9 ОКТЯБРЯ
«ТАТАРСТАН»**

7.00-8.00 "Чулпан"
18.20 "Спорт мәйданчыгы"
18.30 "Служба 01"
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00 "Сәхнә"
19.45,21.45 "Новости"
20.00 "ЦУМ приглашает..."
20.05 "Банк Заречье информирует..."
20.15 "Әлли - бәлли - бәү"
20.30 "ГАИ - информ"
21.00 "Ребро Адама".
22.30 "Вопросы из записной книжки"

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.00 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба".
10.00 Человек и закон.
10.30 Пока все дома.
11.05 Смак.
11.25 Домашняя библиотека.
11.30 19.35 "Угадай мелодию".
15.20 "Драконы подземелий".
15.45 Волшебный мир, или Синема.
16.10 Лего-го!
16.35 "Космическая полиция".
17.05 ...До шестнадцати и старше.
17.30 "100 лет приключений"
19.00 Погода.
19.10 Час пик.
20.00 "Чтобы помнили..."
20.45 Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.45 "Приходите завтра..."
23.35 "Каскадеры. Мир трюков".
0.15 "Дикие пальмы"

**"РОССИЯ"**

7.10 "Дон Кихот Ламанчский". Мультсериал.
7.35 "Стронг" представляет.
7.40 23.20 Вовремя.
7.45 Монетный двор.
8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
8.20 "Дежурная часть".
8.35 18.55 "Жизнь Дэвида Копперфилда, рассказанная им самим".
9.35 18.40 "История одного события".
10.00 17.25 "Санта-Барбара".
11.20 Национальный интерес.
11.50 Городок.
12.20 Старая квартира. Год 1956.
13.15 Музыка на десерт.
13.30 "Люди и деньги".
13.55 "Магазин недвижимости".
14.20 "Деловой автограф".
14.25 "ТИ-Маркет".
14.30 "Черный аист".
16.10 Графоман.
16.20 "Лучше не бывает".
16.25 "Эксповестник".
16.30 Ваше сословие.
17.20 "Православный календарь".
18.20 Лукоморье
20.35 Национальный интерес.
21.10 "Тайна Сахары". 1-я серия.
22.15 Сам себе режиссер.
22.50 "Мой Пушкин".
23.25 Добрый вечер.
0.10 "Дежурная часть".
0.30 Кафе Обломов.

**ПЯТНИЦА,
10ОКТЯБРЯ
«ТАТАРСТАН»**

7.00 - 8.00 "Чулпан"
17.05 Мультфильм
17.20 "Баскетбол, мы тебя любим!"
17.50 "Чужие здесь не ходят" 18.45 "Җиһан"
19.20 "Дин һәм тормыш"
19.45 Новости
20.00 На празднике "Урожай - 97"

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 18.00 0.10 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба".
10.05 Клуб путешественников.
10.50 Мультфильм.
11.10 Домашняя библиотека.
11.20 Телеигра "Эти забавные животные".
15.20 Фильм-сказка "Иван да Марья".
16.55 "Улица Сезам".
17.25 "50 x 50".
19.15 Здоровье.
19.45 Поле чудес.
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.45 "Кого убила капля никотина?".
23.25 Взгляд.
0.20 "Русский бизнес".

**"РОССИЯ"**

7.10 "Дон Кихот Ламанчский".
7.35 "Стронг" представляет.
7.40 23.20 Вовремя.
7.45 Монетный двор.
8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
8.20 "Дежурная часть".
8.35 18.55 "Жизнь Дэвида Копперфилда, рассказанная им самим".5-я серия.
9.35 18.40"История одного события".
10.00 17.25 "Санта-Барбара".
11.20 Национальный интерес.
11.45 "Торговый дом "Ле Монти".
12.00 "Аншлаг" и Ко.
12.55 Репортер."Цыгане".
13.25 "Красная книга".
13.55 "Магазин недвижимости".
14.20 "Деловой автограф".
14.25 "Регион Кузбасс".
14.30 "Ныне прославися сын человеческий".
16.10 Графоман.
16.20 "Лучше не бывает".
16.25 "Эксповестник".
16.30 Парламентарий.
16.55 Прогноз погоды.
17.20 "Православный календарь".
18.20 Лукоморье
20.35 L-клуб.
21.10 "Тайна Сахары".
22.15 Слабо?
22.50 "Мой Пушкин".
23.25 Добрый вечер.
0.10 "Дежурная часть".
0.25 Лестница в небо.
0.55 Пресс-конференция президента компании "Майкрософт" Билла Гейтса.
1.20 Ночная жизнь городов мира.

**СУББОТА,
11 ОКТЯБРЯ
«ТАТАРСТАН»**

7.00 - 8.00 "Чулпан"
17.25 "Точка, точка, запятая..." 18.45 "Җиһан"
19.00 "Бизнес TV"
19.35 Из "личной жизни..." дома
19.45 Новости
20.00 "Точка опоры"
20.20 " Видеоспорт"
20.35 "Әлли - бәлли - бәү"
20.50 "Агым" программасы
21.10 "Зәлидә"
21.40 "Досье 02"
22.00 "Музыкаль сәхифә"
22.25 "Обычная суббота"

**ОРТ**

7.40 "Особо опасные".
9.05 Мультфильмы.
9.40 Лотто-Миллион.
9.45 Слово пастыря.
10.00 15.00 Новости.
10.10 Домашняя библиотека.
10.30 Утренняя почта.
11.10 "Каламбур".
11.45 Смак.
12.05 Возвращение Третьяковки. История одного шедевра.
12.30 "Два Федора".
13.55 За околицей столицы.
14.25 Очевидное - невероятное.
15.20 Моя семья: год спустя.
16.00 "Союзмультфильм" представляет...
16.40 В мире животных.
17.20 "Как это было" .
18.00 Новости.
18.20 Джентльмен-шоу.
19.00 "Спрут".
20.05 "Эти забавные животные".
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
22.00 "Стой! А то мама будет стрелять".
23.35 КВН-ассорти.
0.05 "Дикие сердцем".

**"РОССИЯ"**

7.55 "Фрам-полярный медведь".
8.50 Мультфильмы.
9.05 "Меморина".
9.30 Парламентский вестник.
10.00 Доброе утро, страна!
10.45 "Ваш партнер".
11.00 Вести в одиннадцать.
11.20 "Под сенью пяти колец".
12.00 Крестьянский полдень.
12.25 "Троица" Андрея Рублева".
12.30 "Российским курилам - 3 века".
12.45 Федерация.
13.15 Новое пятое колесо.
13.40 "2005 год".
14.00 20.50 Вести.
14.20 Телескоп.
14.48 Телеафиша.
14.50 "Встречная полоса".
15.05 "Учитель года России".
15.35 "У всех на устах".
16.00 Надо жить играючи.
16.15 "На дорогах России".
16.30 "Это Москва".
17.00 Вести про...
17.20 Бесконечное путешествие.
17.50 "Испанский танец" из балета П.И.Чайковского "Лебединое озеро".
18.00 Совершенно секретно.
18.55 Футбол. Отборочный матч чемпионата мира-98.
21.25 Городок.
22.00 "Дорога в будущее".
23.00 "Любовь с первого взгляда".
23.40 Программа "А".
0.10 Тихий дом. Программа С.Шолохова.
0.35 Живая коллекция.

**ВОСКРЕСЕНЬЕ,
12 ОКТЯБРЯ
«ТАТАРСТАН»**

7.00 - 8.00 "Чулпан"
18.35 "Минем җырлыйсым килә"
19.00 "ТОН"
19.40 "Автокалейдоскоп"
20.00 "Телебуклет"
20.15 "Әлли - бәлли - бәү"
20.35 Харис Нигъмәтҗановның иҗат кичәсе
21.35 "Тулган ай яктысында" 22.10 "СИРЕНЫ"
22.55 Программа передач.

**ОРТ**

7.40 "Двое под одним зонтом".
9.15 Мультфейерверк.
9.55 Спортлото.
10.00 15.00 Новости.
10.10 "Непутевые заметки"
10.30 Пока все дома.
11.10 Утренняя звезда.
12.00 Служу России!
12.30 Играй, гармонь любимая!
13.00 Сельский час.
13.30 "Подводная одиссея команды Кусто".
14.20 Смехопанорама.
15.20 Клуб путешественников.
16.05 Футбольное обозрение.
16.35 Большой мультфильм.
18.00 "Колесо истории".
19.00 "Особенности национальной охоты".
20.50 Киноафиша.
21.00 Время.
21.40 "Крепкий орешек".
0.00 Экспрессия танца. Борис Эйфман.
0.30 Новости.
0.45 "Народный роман".

**"РОССИЯ"**

7.55 "Фрам-полярный медведь".
8.50 Мультфильмы.
9.30 Присяга.
10.00 Доброе утро, страна!
10.45 Компьютер.
11.00 Вести в одиннадцать.
11.20 Русское лото.
12.00 Пульс.
12.30 Фестиваль региональных программ.
12.45 "Люди и деньги".
13.10 Двойной портрет.
13.40 "Музыкальный экспромт".
14.00 Вести.
14.20 Праздник моды
15.50 Репортер.
16.20 "Довгань-шоу".
16.50 Диалоги о животных.
17.05 Волшебный мир Диснея.
17.55 Прогноз погоды.
18.00 "Игра всерьез".
18.25 "Возвращение к папуасам".
18.55 "Аншлаг" и Ко.
20.00 Зеркало.
21.05 "Тайна Сахары".
22.10 Футбол без границ.
22.40 "Колизей".
23.35 Русский бой.
0.30 У Ксюши.
1.00 Подиум Д"Арт.



# БӘЙРӘМ БЕЛӘН СЕЗНЕ, КАДЕРЛЕ УКЫТУЧЫЛАР!



Миннеәсма Билаловна Сафиуллина белгечлеге буенча математика укытучысы.Өч дистә еллап балаларны бу төгәл фән серләренә өйрәтте ул.Ә инде мәктәптә татар теле укытучыларына кытлык тугач, дирекция үтенече буенча квалификациясен үзгәртеп,балаларга татар теле укыта башлады.Билгеле инде,җиңел нәрсә булмады бу аның өчен.Өстәмә рәвештә дистәләгән әдәбиятны карап-барлап чыкты,үз куллары белән дидактик һәм күргәзмә әсбаплар ясады,мәктәпнең барлык укучыларын да уку әсбаплары белән тәэмин итү хәстәрен күрде.Хәзер Миннеәсма Билаловна 5-11нче сыйныфларда укучы татар балаларын үз ана телләрендә яхшы итеп укырга,язарга өйрәтә.Табигате буенча сабыр,үтә тыйнак педагог балаларда татар теленә мәхәббәт тәрбияләү,аларны үз милләтләре патриотлары итеп тәрбияләү өчен зур көч куя.

**Рәсемдә:Чулпан урта мәктәбе укытучысы М.Б.Сафиуллина.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## Бөтенесе алар турында

Минем газета укучыларына ике педагог турында сөйлисем килә.Бу хатын-кызлар арасында яшь аермасы бар һәм алар төрле коллективларда эшлиләр. Әмма аларны бик күп нәрсә берләштерә.Алар балалар укыталар һәм тәрбиялиләр, өлкәннәрнең ихтирамын казанган кешеләр.

Валентина Викторовна Сувальдо үзенең бөтен гомерен балаларга багышлады.Укытучы да, тәрбияче дә,балалар бакчасы мөдире дә булып эшләде.Эш стажы? Бөтен гомере.Бүләкләре-юбилей медале, В.И.Ленинтууына 100 ел булу уңаеннан бирелгән медале дә бар,хезмәт ветераны һәм мәгариф отличнигы исемнәренә лаек.Әлеге бүләкләр үзләре өчен үзләре сөйли.Ул үрнәк ана, ике кыз тәрбияләп үстерде. Шикәр заводы микрорайоны кешеләре аны җәмәгать эшлеклесе буларак беләләр-берничә кат халык утырышчысы,халык депутатларының Норлат шәһәр Советы депутаты,хатын-кызлар район Советы әгъзасы итеп сайланды.Үзешчән сәнгатьтә дә актив.Кешеләр һәм балалар белән итәгатьле,йомшак,шул ук вакытта катгый да була белә.«Пчелка» балалар бакчасы коллективы, предприятие җитәкчелеге арасында абруй казанды-эшендә аны яраталар, бәялиләр.Ата-аналарның да бу хатын-кызга ихтирамнары зур.Валентина Васильевна 81 яшьлек әнисен дә зур кайгыртучанлык белән карый.Сувальдо гаиләсе бердәм,аның ире Вадим Владимирович хатыны өчен зур ярдәмче.

Галина Афзаловна Ризвнованың хезмәт стажы-чирек гасыр. Шәһәрнең 8нче урта мәктәбендә химия укыта ул.Балаларга билгеле күләмдә белем бирүдән тыш,аларда химиянең кеше эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә роле зур булуын төшендерергә омтыла.Ә аның дәресләре? Алар практик юнәлешкә ия.Күргәмә әсбаплар, индивидуаль эш,мөстәкыйль заданиеләр, лаборатор дәрес-болар барысы да Галина Афзаловнага барлык балаларның да эштә катнашуына ирешергә булыша.Укыту алымнары да төрле: дәрес-семинарлар,белемне тематик исәпкә алу һ.б.

Ул химия буенча факультатив курслар да алып бара,кичәләр һәм викториналар үткәрә. Бу хатын-кызның бар нәрсәгә дә вакыты җитә. Ул үз өстендә даими эшли,ата-аналар белән очраша, җәмәгать эшендә актив.Хәзер ул мәктәп директорының укыту эшләре буенча урынбасары.Галина Афзаловна бу вазифаны бик яхшы башкара.

Бәйрәм белән сезне,Валентина Викторовна һәм Галина Афзаловна! Саулык-сәламәтлек сезгә.

**А.СПИРЧАГОВА.**

## Рәхмәтебез зур

Безнең өч балабыз да «Теремок» балалар бакчасына йөреп үстеләр.

Моннан нәкъ 15 ел элек, олы кызыбыз Катяны җитәкләп атлап кергән идек без бу йортның бусагасын. Аннары бирегә уртанчыбыз Алеша йөрде, быел менә төпчегебез Дмитрий өчен дә тәүге мәктәп кыңгыравы чыңлады инде.

Шул елларда «Теремок» коллективы балалар тәрбияләүдә гаиләбезнең иң ышанычлы һәм игелекле ярдәмчесе булды. Балаларыбызга күңел җылыларын кызганмаган ул яхшы кешеләрне һич тә онытасыбыз юк. Шуңа да бу көнне «Теремок» балалар бакчасының барча коллективын һөнәри бәйрәмнәре белән котлыйбыз, аларга ныклы тазалык - саулык, эшләрендә уңышлар, шәхси тормышларында бәхет - куанычлар телибез.

Зур рәхмәт сезгә!

**Фадеевлар гаиләсе.**

## Остазлар

Һәр мәктәпнең йөзен билгели торган әйдәп баручы остаз мөгаллимнәре була.Киекле татар мәктәп-гимназиясе коллективында да бар андый остазлар.

Укытучы-методист, Мәгариф отличнигы укыту эшләре буенча директор урынбасары Кафия Хәмәтсафа кызы Фәссахова Киеклегә Апас районының Урта Балтай авылыннан килен булып төшә.Урта мәктәпне көмеш медаль белән тәмамлаган кыз үзенең яраткан укытучы апалары-Рево Һадиевна һәм Нажия апа Гобәйдуллина күк математика фәненә гашыйк була.Математика төгәллекне,тиз фикер йөртү сәләтенә ия булуны таләп итә.Шуның өстенә үз белемеңне тагын да үстерергә, математиканың күп санлы формулаларын,закончалыкларын,кагыйдәләрен истә тотарлык хәтер булдырырга кирәк булган аңа.Тырыш,максатчан булуы нәтиҗәсендә тирән теоретик белемгә ия була. Үз фәнен балаларга өйрәтүнең иң отышлы алымнарын,юлларын табарга тырыша.32 ел педагогик стажы булган ветеран укытучы үзе белгәннәрне яшьләргә өйрәтү,тапшыру буенча бик зур эш башкара.Коллективтагы һәр яшь укытучыга чын педагог булып җитешергә ярдәм итте безнең Кафия апабыз.Ул дәрескә укытучыны тикшерү өчен генә йөрми,ә үз алдына һәрчак укытучының эшендәге иң уңышлы алымнарны билгеләүне,аның профессиональ мөмкинлекләрен,сәләтен,методик ярдәмгә мохтаҗлыгын ачыклауны максат итеп куя.

Без яши торган заман тырышып эшләүне таләп итү белән бергә,тирәнтен фикер йөртә белү,мәктәптә иҗади халәт булдыру,яшь буын турында кайгырту бурычын куя.Менә шуларны истә тотып,остаз мөгаллимә белем һәм тәрбия эшен яңача оештырырга кирәклеген аңлап,яшьләрне һәр баланың шәхесендә аңа гына хас булган,кабатланмый торган сыйфатларны күрә һәм аны укыту-тәрбия эшендә исәпкә ала белергә өйрәтә.

Кафия Хәмәтсафовна фикеренчә,укытучы үзе укыта торган фән,философия,физиология, психология,социология,педагогика өлкәсендә белемле булырга,укучының аң-фикер эшчәнлеге формалашу һәм үсү процессын,баланың сәләтен,укыту-тәрбия эшендә төрле хәлләргә очраганда,үзүзеңне ничек тотарга кирәклекне дә өйрәтә.

Эстониянең Таллин шәһәрендә хәрби хезмәткәр гаиләсендә туган Роза Хәлиулла кызы Әһлиуллинада укытучы булу теләге Аксубай районы Кыязлы мәктәбенә кайтып укый башлагач кабына.Кизләү урта мәктәбен тәмамлау белән үк мәктәпкә килә.Елдан-ел үзенең педагогик сәләтен чарлый,белем туплавын дәвам итә, методикасын булдыра.

Мәгариф отличнигы,Татарстанның атказанган укытучысы белемле, әдәпле,уңган, тыйнак,максатка ирешүчән, яшь буынны тәрбияләүдә туплаган тәҗрибәсе белән һәрчак бик теләп уртаклаша.

**( Ахыры 4 нче биттә).**

## ҺӘРВАКЫТ ЭЗЛӘНҮДӘ



Таныш булыгыз:рәсемдә Якушкино урта мәктәбенең тәҗрибәле укытучыларыннан берсе Ю.М.Романова.Алабуга дәүләт педагогия институтын тәмамлады ул.Бирeдә башлангыч классларны укыта:белемле,даими эзләнүче,диләр аның турында коллективта.

Юлия Максимовнаның хезмәт стажы ике дистә елдан артык.Укытучы-методист ул.

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

**Энҗе Мөэминова**

## *Укытучыма*

Хәтерлим мин,әле бүгенгедәй,
Сентябрьнең бере җиткәнен.
Хәтерлим мин,әле бүгенгедәй,
Көтә-көтә арып беткәнем.

Иң беренче булып килим,диеп,
Өскә матур яңа күлмәк киеп,
Хәтерлим мин,әле бүгенгедәй,
Ашыга-ашыга чыгып киткәнем.

Ләкин миннән бик күп алдан килеп,
Хуш киләсең,әйдә,әйдә,диеп,
Хәтерлим мин,әле бүгенгедәй,
Укытучы апам көткәнен.

Шушы көннән башлап безнең өчен
Кызганмады үзенең бөтен көчен.
Безне сөйде,безгә белем бирде,
Рәхмәт аңа изге эше өчен!

# Остазлар

( Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Методик киңәшмәләрдә, үткәргән ачык дәресләрендә остаз яшь хезмәттәшләренә дәреснең дидактик максатына ирешү, укыту процессында укучылар белән кире элемтәне булдыру, балаларның дәрестә танып-белү эшчәнлеген активлаштыру алымнарын куллану, үзара ярдәмләшү, дәрестә акыл, эстетик тәрбияне гамәлгә ашыру серләрен ачарга булыша.

Ә менә Кашаповлар гаиләсе Киеклегә Биләр-Озеро мәктәбеннән күчеп килделәр. Гаилә башлыгы Ильяс Хөҗҗәтович очраклы рәвештә педагог булып киткән. Геолог булырга хыялланган һәм инде геологик экспедицияләрдә катнашкан егетне сайлаган һөнәрен укытучы хезмәтенә алыштырырга нәрсә мәҗбүр иткән соң? Матурлыгы белән генә түгел, искиткеч акыллылыгы, киң эрудициясе белән башкалардан бик күпкә аерылып торган укытучы кыз Тәнзиләгә мәхәббәте сәбәп булган моңа.

Мәктәпкә килгәч тә балалар дөньясы үзенә бөтереп алып кереп киткән аны. Укыту-тәрбия эшен камилләштерүдә педагогик психологик белемнәр гаять зур әһәмияткә ия булганлыгына инанган Ильяс Хөҗҗәтович үзе җитәкләгән коллективта педагогия һәм психология буенча укулар оештырып, бу өлкәдә тупланган белемнәрне һәр укытучыга җиткерүне максат итеп куйды. Үзе башлап яңа төр дәрес үрнәкләре күрсәтте. Дәрес-семинар, конференция, зачет үткәрү методикасы белән таныштырды.

Математикларны, физикларны үз эченә алган методик берләшмәнең җитәкчесе Тәнзилә Гыйләҗевна Кашапова иҗади эшләүче педагогларыбызның тәҗрибәсен тарату буенча бик күп эш башкарды. Аның тырышлыгы белән новатор укытучылар Ефремов, Шаталов методикасы турында үзара фикер алышулар үткәрелде, аларның нәтиҗәле методларын ничегрәк итеп дәресләрдә иҗади файдалану мөмкинлекләре ачыкланды. Нәтиҗәдә күп кенә мөгаллимнәр программа материалын блоклап өйрәнү методикасы, терәк сигналларны уңышлы куллану алымнары белән таныштылар.

Менә шундый үз эшенә бирелгән, яшьләрчә зур дәрт белән иҗади эшләүче педагоглар укучыларга ныклы белем, тормыш тәҗрибәсе һәм тәрбия бирүдә яшь мөгаллимнәрнең иң зур терәге булып торалар.

**Флера ВӘЛИУЛЛИНА, укытучы.**

# «Актив булсыннар, иҗади эшләсеннәр»

«Ватанын, үз халкын, хезмәтне яратучы, актив, иҗади эшләүче шәхес тәбияләү». Безнең Кизләү мәктәбендә балаларны тәрбияләүдә нигез итеп шушы девиз алынды. Ә тәрбия эше үзәгендә халык педагогикасы ятты. Мәктәп күләмендә һәм аерым классларда эшләнгән план буенча һәр чарада үсеп килүче яшь буында патриотизм хисе, милли үзаң, халыкның тарихы белән кызыксыну тәрбияләүдә бәйле булган нәтиҗәле алымнар кулланылды.

Шунысы куанычлы, педагогик коллектив билгеләнгән бурычны үтәү өчен барысын да эшләде.

«Тел, халык иҗатына сәяхәт» (үткәрүчесе М.С.Курамшина), «Фольклото» (Л.Я.Курамшина), «Әлифба бәйрәме» (Г.Н.Усманова) кебек чаралар балаларның киң катнашында үтте. Бөтен класс укучылары катнашында үткәрелгән «Уңыш бәйрәме», «Аулак өй», «Нәүрүз» һ.б. чараларны да балалар бик ошаттылар.

Хезмәт, сәламәтлек, гаилә һәм бала, сәнгать, тынычлык айлыклары да тирән тәрбияви мәгънәгә ия булды. Шулар кысасында уздырылган фән атналыклары да балалар күңеле өчен бик тәэсирле булды. Ә әзтабарлар, итагатьлелек, экология атналыкларында укучыларның ничек актив булганнарын күрсәгез иде әле сез!

Укучыларның кызыксынуларыннан чыгып оештырылган төрле түгәрәкләр дә төбәгебез халкы тарихын өйрәнергә, кече Ватанына мәхәббәт тәрбияләүгә хезмәт итүдә аз роль уйнамагандыр, мөгаен. Үз осталыкларын арттырып, теге яки бу эшкә сәләтләрен үстереп кенә калмадылар, түгәрәкләрдә йөргәндә алган белемнәрен күрсәтү мөмкинлекләре дә булды аларның. Әйтик, «курчак театры» түгәрәгенә йөрүчеләр шәһәр үзәгендә үткәрелгән «Әкият дөньясында» фестивалендә катнашып, өченче урын яуладылар. «Кул эшләре, «Оста куллар» түгәрәген үз итүчеләр күргәзмә оештырдылар. «Яшь турист» түгәрәге активистлары исә яшь туристлар район слетында беренче булдылар. Мәктәп янына утыртылган 50ләп алмагач, 70 ләп декоратив агач та мәктәбебез укучыларының куллары белән башкарылган эш иде.

Тулаем уку дәвамында традицион конкурс-ярышлар «Брейн-ринг», «Йолдыз сәгате» һ.б. да балаларның киң катнашында үтте. Укучы[illegible] Илһамия Низаметдинованың шигырьләре «Яшь иҗатчы» район конкурсында беренче урынга лаек дип табылуы да мәктәп өчен сөенеч өстенә сөенеч булды.

Яңа уку елы башланды. Безнең педагогия коллективы узган ел алга куелган бурычка тугры калып, аны дәвам итterүне, алай гына да түгел, эзлекле үстерүнә, шулай итеп үз халкын, Ватанын сөюче, үз милләте патриоты булган шәхес тәрбияләүне максат итәләр.

**Х.КУРАМШИН.**

## Чулпан авылы укытучыларына

***Кадерле укытучыларым. Мин сезгә үземнең рәхмәтемне белдерәм. Сез безгә кешенең дөньядагы урынын һәм нәрсәләргә ышанырга тиешлеген өйрәттегез. Сез биргән белемнәр белән мин төрле этапны узам, баскычтан баскычка күтәреләм. Безне Ватанны яратырга өйрәттегез. Балаларга белем бирү, аны үстерү-сез укытучыларның изге бурычы. Икенче яктан, белемле кешеләр үстереп, сез дәүләткә дә кирәкле ярдәм күрсәтәсез.***

***Рәхмәт укытучыларыма!***

**Алабуга педагогия институтының I курсның 742 группасы укучысы ӘНДӘРҖАНОВА ГӨЛНАЗ.**

# Тракторчы гына түгел, хуҗабикәләр дә

**Районда яшьләргә профессиональ белем бирүче бердәнбер уку йорты булган 99нчы профессиональ училищеда җәйге каникуллардан соң гадәти эш ритмы урнашты: биредә укулар башланды. Училище курсантлар җыю планын үтәдеме, укытучы-мастерлар белән тулы комплектланганмы? Бу һәм башка яңалыклар турында училище директоры Р.Р.Алякимов сөйли.**

-Уку елы гадәттәгечә уңышлы башланды. Быел беренче курска 80ләп яшүсмерне кабул иттек. Тәмамланмаган урта белемгә ия укучылар биредә өч ел дәвамында белем алып, тракторчы-машинист, слесарь, АВС категорияле шофер белгечлекләренә ия булачаклар. Бер үк вакытта урта белем турында документ та алачаклар.

Калган ике курста 100дән артык яшүсмер укуларын дәвам иттерәчәкләр. Шуларның 47се бухгалтер, 27се пешекче булырга әзерләнәләр. Октябрьдән санитар-ветеринар белгечлеге буенча да укучылар комплектлый башлаячакбыз. Тагын 60лап кеше исә кичләрен шоферлыкка укыячак. Шунысын да әйтәсем килә, бу категория курсантларга һөнәр үзләштерү өчен шактый күләмдә акча түләргә дә кирәк булачак быел.

Башка еллардагыдан аермалы буларак, быел тәүге тапкыр «йорт яны хуҗабикәсе» дип аталган төркем ачылды. Бирегә без урта мәктәпнең тугызынчы классын тәмамлаган кызларны кабул иттек. Алар бездә өч ел эчендә өч һөнәр үзләштерәчәкләр һәм яшелчәче дә, пешекче дә, бухгалтер да булып эшли алачаклар. Берүк вакытта училищедан урта белем турында документ та алып чыгачаклар әле. Училищеда укыту-тәрбия процессын оештыру, курсантларны тукландыру мәсьәләсе дә хәл ителде. Бездә укучылар көнгә ике тапкыр бушлай ашатылалар, өстәвенә стипендия дә алалар. Дөрес, яңа бина төзелеп бетсә (төзелештә эш финанслар булмау сәбәпле тукталды) училищеда занятиеләрне өч сменада алып барып, педагоглар, шулай ук курсантларның үзләре өчен өстәмә кыенлыклар тудырмас идек. Уку мастерскойларыбыз булса, курсантларыбыз практик күнекмәләрне дә үзебездә үк үзләштерә алырлар иде. Югыйсә, ничарадан-бичара булып, аларны «Сельхозтехника» АҖ мастерскойларында, турыдан-туры хуҗалыклар басуларында эшкә өйрәтергә мәҗбүрбез. Ахыр чиктә бинаны төзеп бетереп, аны агролицейга әйләндерү, шулай итеп, районыбыз яшьләре өчен район чикләреннән чыкмыйча ук авыл хуҗалыгы белгечлекләре үзләштерү кебек якты хыялыбызга якынайтыр иде.

Педагогия кадрларыбызга килгәндә, коллективыбызның стабиль, бердәм булуын зур горурлык белән билгелисем килә. Укытучылар Д.И.Ефремов, Ф.Г.Гаязов һәм В.М.Гыймранов, мастерлар А.Л.Харитонов, Х.С.Гатин һәм М.Ю.Хөснетдиов яныпкөеп эшләп йөрүче кешеләребез. Төп максатлары-бүгенге көндә авыл хуҗалыгында теләсә нинди техникага утырып эшләрлек кадрлар хәзерләү.

## Рәхмәт белдерәбез

**Бу хәсрәтебезне аңлатырдай бернинди дә сүз таба алмыйбыз. Сөекле улыбыз Геральдның фаҗигале рәвештә һәлак булуы йөрәкләребезне телгәли.**

**Шушы авыр көннәрдә безгә мораль һәм матди ярдәм белән булышкан, кайгыбызны уртаклашкан район хакимияте, мәгариф бүлеге, Киекле җирле үзидарә Советы, Кизләү һәм Киекле урта мәктәпләре, НУАД, НГДУ хезмәткәрләренә, барлык авылдашларга, туганнарыбызга, дусларыбызга, улыбызның класссташларына, элеккеге укучыларыбызга олы рәхмәтебезне белдерәбез. Беркемгә дә мондый ачы хәсрәтне күрергә язмасын.**

***Хәмитовлар гаиләсе.***
***Кизләү авылы.***

# Белдерүләр

## Сатабыз

**Суы, җимеш агачлары булган дача, кыйммәт түгел.** Адрес: Электростанция ур., 3 - 51 (кичке 4 тән соң).

***

**1996 елның августында чыккан ВАЗ -21213 «Нива».** Адрес: Спартак ур.,2.

***

**1983 елгы ВАЗ - 2103.** Тел.: 3 - 52 - 35, 3 - 52 - 46.

***

**ВАЗ - 21011 һәм ИЖ - Юпитер - 5 мотоциклы, кыйммәт түгел**. Тел.: 2 - 20 -69.

***

**1990 елгы, биш тизлекле ВАЗ - 2105, 1984 елгы ВАЗ - 2107.** Адрес: Кошка авылы, Мир ур., 38, тел.: 2 - 21 - 41.

***

**1992 елгы, кулланылышта булган ВАЗ -2106 кузовы.** Адрес: Төзүчеләр ур., 27 -1.

## Хөрмәтле сатып алучылар!

**«Китаплар» кибетенең беренче катында ачылган «Мехлар» кибетендә хатын -кызлар, ир - атлар һәм балалар өчен киң ассортиментта мех әйберләр бар.**

## Алмаштырабыз

**Бер бүлмәле фатирны - шундыйга ук.** Чапаев ур.,6 -20 адресы буенча Миннегөл Кадыйровага мөрәҗәгать итәргә.

***

**Самараның 16 нчы микрорайонындагы өч бүлмәле аерым фатирны (уңайлатылган планировка, 40/63 квадрат метрлы, 10 катлы кирпеч йортның 10нчы катында) - килешү буенча Норлатта уңайлатылган планировкалы 2 бүлмәле аерым фатирга яки газ ягып җылытыла торган йортка.**

Адрес: Совет ур., 102 - 9.

## Фатир кирәк

**Яшь гаиләгә 1 яки 2 бүлмәле фатир кирәк.** Островский ур., 3б адресы буенча мөрәҗәгать итәргә.

## Идел Буе региональ наркология үзәге

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.* ***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көннәрендә, 10 октябрьдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.

«Татнефтедор»ООО сының НУАД коллективы ире Геральд Фаикъ улы Хәмитовның фаҗигале үлүе уңаеннан АЗС операторы Мәүлия Вахит кызы Хәмитованың авыр хәсрәтен уртаклаша.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **Д.Ф.ТӘМАЕВА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә.